Республика Татарстан

**ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан Республикасы

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**“ 30 ” 05 2019г.** **№ 47**

“Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы муниципаль контролен
гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын
бәяләү күрсәткечләре исемлеге турында”

2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 294-ФЗ номерлы Федераль законга, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 20 апрелендәге «2018 ел нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан башкару дисциплинасының торышы, халыкның тормыш сыйфатын һәм аның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары белән идарә итүгә Дәүләт йөкләмәсен үтәү турында”гы №324 карары нигезендә карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү күрсәткечләрен расларга.

Кушымта:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль контролен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын бәяләү күрсәткечләре исемлеге.

**Р.М. Нуриев**

М.В. Ларин
2-74-14

Кушымта №1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль контроль нәтиҗәлелеген һәм эффектлылыгын гамәлгә ашыру күрсәткечләре исемлеге

.

Күрсәткечләр:

*1.Еллык күрсәткеч:* узган елга карата муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның профилактик чаралары санының үсеше,%.

V= A/B х 100 %

А - агымдагы елда үткәрелгән профилактик чаралар саны;

В - узган елда үткәрелгән профилактик чаралар саны.

*2. Еллык күрсәткеч:* төзекләндерү кагыйдәләрен бозган очракта, закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зыян китерү фактларының кимүе, %.

V = (А / В -А 1 / В 1) х 100

А - узган елда муниципаль төзекләндерү кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны, берәмлек (Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турында кодексының 3.6 маддәсе);

А1 - агымдагы елда төзекләндерү муниципаль кагыйдәләрен бозган өчен административ штраф салу турында төзелгән беркетмәләр саны, берәмлек (Татарстан Республикасы административ хокук бозулар турында кодексының 3.6 маддәсе);

В - узган елда үткәрелгән планлы рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг);

В1 - агымдагы елда үткәрелгән планлы рейд тикшерүләре саны (системалы мониторинг), бер.

*Квартал күрсәткече:* аларны гамәлгә ашыру буенча административ регламентлар кабул ителгән муниципаль контроль төрләре өлеше, муниципаль районда (шәһәр округында) контроль төрләренең гомуми саныннан, %.

V= A/B х 100 %

А - муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча кабул ителгән административ регламентлар саны;

В - муниципаль контрольнең расланган төрләре.